# Апас ягы

*Хәлим Гайнуллин сүзләре*




нур си - беп бә - хет та - ны.
Йө - рәк - ләр - дә жыр я - на - ра, чир - теп кү - нел
кыл - ла - рын. Хез - мәт бе - ләң гөр - ләп у - за
Кы - зыл Тау - да яшь - лек ел - ла - ры.




1971

Язын Бола ярларында
Тынмый дулкыннар шавы.
Туган якта таң сызыла,
Нур сибеп бәхет таңы.

К у ш ы м т а:
Йөрәкләрдә җыр яңара,
Чиртеп күңел кылларын.
Хезмәт белән гөрләп уза
Кызыл Тауда яшьлек елларым.

Таң җилләре тибрәндерә
Алтын иген кырларын.
Син үстердең, Апас ягы,
Зур хезмәт батырларын.

К у ш ы м т а.

Онытмыйк без, авылдашлар,
Зәңгәр, айлы кичләрне.
Ядкарь итеп саклыйк мәңге
Якты, матур хисләрне.

К у ш ы м т а.

Илдә икмәк мул булсын дип,
Кайнар тирләр түгелә.
Кызыл Тау, Тутай кырлары
Шат җырларга күмелә.

К у ш ы м т а.